# РӘВЕШ

## Рәвеш турында төшенчә

Азнакай шәһәре 3 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең беренче категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Тинбакова Римма Варис кызы

# Рәвеш турында төшенчә

Сораулар:

1. Рәвеш нәрсәне ачыклый?
2. Рәвеш нинди сорауларга җавап бирә?
3. Рәвешнең нинди төркемчәләре бар?



Яз галәмәтләре. Харисова Д., Азнакай шәһәре 3 нче урта мәктәбе укучысы

## 1нче бирем

Сез белгән сүз төркемнәрен билгеләгез
Алар нинди сорауларга җавап бирә?
Кайсы сүз төркемен ачыклап килә?

- Якты кояш туры карый.
- Күчмә кошлар озакка кайттылар.

- Югарыда аларның тавышы ишетелә.
- Көн бүген җылытып җибәрде.

- Төн көзгедәй салкын булды.
- Салкын кыш ачудан китмәскә тартыша.

Нәтиҗәдә түбәндәге схема килеп чыга:

Якты(сыйфат) кояш(исем) туры(???) карый(фигыль).

ягъни:

сыйфат ?

исем фигыль

2нче бирем
Кара белән билгеләнгән сүзләргә фигыльдән чыгып нинди сораулар куела?
Әлеге сүзләр фигыльне кайсы яклап ачыклый?

- Якты кояш **туры** карый.
- Күчмә кошлар **озакка** кайттылар.
- **Югарыда** аларның тавышы ишетелә.
- Көн **бүген** җылытып җибәрде.
- Төн **көзгедәй** салкын булды.
- Салкын кыш **ачудан** китмәскә тартыша.

Димәк:

1. Рәвешләр эш яки хәлнең билгесен белдәрә.

2. Ничек? күпме? кайчан? кайда? кая? нигә? сорауларына җавап бирә.

3. Эш яки хәлнең үтәлү урынын, вакытын, күләмен,максатын яки сәбәбен, ысулын яки рәвешен белдерә.

# Рәвеш төркемчәләре:

- 1.Саф рәвешләр(тиз,салмак,тын);
- 2. Күләм-чама рәвешләре(күп, байтак, еш-еш);
- 3. Охшату-чагыштыру рәвешләре(кышкыдай, аюдай, кояштай);
- 4. Вакыт рәвешләре (кичә, көзен, күптән);
- 5. Урын рәвешләре (еракта, югарыда, ары);
- 6. Сәбәп-максат рәвешләре (юкка, ачудан, юри);

# Ныгыту.

1нче бирем.

Бирелгән сүзләрне укыгыз, рәвешләрне генә сайлап әйтегез. Алар белән җөмләләр төзегез. Сораулар биреп карау юлы белән җавапларыгызның дөреслеген тикшерегез.

Матур, яши, тиз, кайталар, янәшә, куе, саргылт, әдәби, байтак, аюдай, унике, еш-еш, салмак, якында, бүген, кирәккә, юеш, болытсыз, олыларча, сөтле, акрын, ашыга-ашыга, искиткеч, акрын, балалар, ул, юкка гына.

2нче бирем. Бирелгән җөмләләрдән рәвешләрне табып, түбәндәге таблицада нокталар ярдәмендә күрсәтегез .

1. Мине Сабан туе көнне иртүк уяттылар. (Г.Тукай)
2. Ут Вәли байның келәте янындагы буш керосин мичкәсенә күчте. Аннан югары үрмәли башлады. (Һ. Такташ)
3. Борынгы бабаларыбыз аны Идел-йорт дип юкка гына әйтмәгәннәр. (Вакытлы матбугаттан)
4. Бүлмәдә әкрен генә уйналган музыка тавышлары ишетелгәч, Мәрьям җиңел сулап куйды. (Г.Әпсәләмов)
5. Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык,
   Ашап ята бушка гына алар азык. (Г.Тукай)
6. Ә еракта, күк читендә, зәңгәрсу урман күренә. (Л.Ихсанова)
7. Бу гүзәл күренештән күзне алып булмый, караган саен карыйсы килә. (Л. Ихсанова)
8. Хәзер аны бераз ял иттерәсе иде. (И.Гази)
9. Үләннәрдәге чык тамчылары кояш нурларында энҗе бөртекләредәй җемелдиләр. (Җ.Тәрҗеманов)
10. Әллә чынлап, әллә юри генә минем салпы якка салам кыстырырга тотына. (Г. Бәширов)

| Рәвеш төркемчәләре \ №№ | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Саф рәвешләр | | | | | | | | | | |
| Урын рәвеше | | | | | | | | | | |
| Вакыт рәвеше | | | | | | | | | | |
| Охшату-чагыштыру рәвеше | | | | | | | | | | |
| Күләм-чама рәвеше | | | | | | | | | | |
| Сәбәп-максат рәвеше | | | | | | | | | | |

# Куелган нокталарны бирелгән тәртиптә урнаштырыгыз

- Өстән:1- 2 – 4 – 6 – 8 – 10 – 9
- Астан: 1 – 3 – 5 – 8 -10 - 9

# Җаваплар дөрес булган очракта, түбәндәге фигура (балык) килеп чыга

| Рәвеш төркемчәләре \ №№ | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Саф рәвешләр | | | | : | | | | | | : |
| Урын рәвеше | | : | | | | : | | | | |
| Вакыт рәвеше | : | | | | | | | : | | |
| Охшату-чагыштыру рәвеше | | | | | | | | | : | |
| Күләм-чама рәвеше | | | | | | | | : | | |
| Сәбәп-максат рәвеше | | | : | | : | | | | | : |
| | | | | | | | | | | |

3 нче бирем.
Бирелгән сүзләрне татарчага тәрҗемә итегез. Татарча сүзләр белән рәвеш + фигыль сүзтезмәләр төзеп языгыз.

*Мало, много, вчера, ближе, красиво, долго, медленно, давно, по-взрослому, зря, редко, далеко.*

# Йомгаклау.

Эш яки хәлнең билгесен белдереп, ничек? күпме? кайчан? кайда? кая? нигә? сорауларына җавап бирәторган мөстәкыйль сүз төркеме рәвеш дип атала.

Рәвеш күбрәк фигыльгә ияреп килә: ерак бардык, иртәгә кайту, тиз сөйләшү.

Рәвеш эш яки хәлнең үтәлү урынын, вакытын, күләмен,максатын яки сәбәбен, ысулын яки рәвешен белдерә.

*Рәвешнең мәгънә төркемчәләре:*

*1.Саф рәвешләр(тиз,салмак,тын);*

*2. Күләм-чама рәвешләре(күп, байтак, еш-еш);*

*3. Охшату-чагыштыру рәвешләре(кышкыдай, аюдай, кояштай);*

*4. Вакыт рәвешләре (кичә, көзен, күптән);*

*5. Урын рәвешләре (еракта, югарыда, ары);*

*6. Сәбәп-максат рәвешләре (юкка, ачудан, юри);*